# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чәкән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**13 октябрь 2023 ел** **№1**

2003 елнын 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 13 октябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

1. «Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаиләләре махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) Чекан торак пунктыдагы урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Чекан торак пунктындагы рус һәм татар зираты территориясен төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

3) Чекан торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Чекан торак пункты халыкның күпләп ял итү урыннарын, аларга якын урнашкан территорияләрны төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 217 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 198.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларнын тавышлары тубәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе очен 198, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - гамәлдә дөрес дип танырга.

2.Түбәндәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаиләләре махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) Чекан торак пункты урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Чекан торак пунктындагы рус һәм татар зираты территориясен төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

3) Чекан торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Чекан торак пункты халыкның күпләп ял итү урыннарын, аларга якын урнашкан территорияләрны төзекләндерү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районынын Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: Г.И. Аскарова